ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 10

Урыссу штб 02.09. 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 25.04.2024 елның 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25.04.2024 ел, № 5 карарына (13.09.2024 ел, № 35, 12.11.2024 ел, № 38, 14.11.2025 ел, № 7, 01.12.2025 ел, № 9, 24.12.2025 ел, № 11 карарлар редакциясендә) (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент.»;

1.2. Карарның 5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламалары салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә салым түләүче сайлаган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.»;

1.3. Карарның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының "Урыссу шәһәр
тибындагы бистәсе" муниципаль
берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының Урыссу
шәһәр тибындагы бистәсе Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин